| МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2014 елның 18 апреле № К-53/03-03

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәрләренә аттестация уздыру турындагы Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге № 110 Указы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” Россия Федерациясе Президентының 19.03.2014 № 156 Указын һәм Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы белән расланган нигезләмәне үтәү йөзеннән, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 17.02.2014 № К-26/03-03 боерыгы белән расланган нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына Министр һәм (яисә) ул вәкаләт тапшырган граждан хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлегеннән, финанс бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле, шулай ук фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның Министрлык гарызнамәсе буенча бәйсез экспертлар – экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә, граждан хезмәте мәсьәләләре белән бәйле белгечләр сыйфатында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган вәкилләре керә. Татарстан Республикасы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары конкурс комиссиясе составына кертү

өчен Министр гарызнамәсе буенча шушы совет тарафыннан тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.»;

б) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую яисә кадрлар резервына кертү йә мондый билгеләп куюдан баш тарту өчен нигез була.

Конкурс комиссиясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.»;

в) 4.4 пунктның 4.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.1. Беренче этапта Министрлык үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасы сайтында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштыра: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы, шушы вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата белдерелә торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта) нигезендә документлар кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документлар кабул итү тәмамлана торган срогы, конкурс уздыруның күз алдында тотыла торган  датасы, конкурсны уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар урнаштыра. Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турындагы белдерү һәм конкурс турындагы мәгълүмат вакытлы матбугат басмасында басылырга мөмкин.

Конкурсның беренче этабы конкурс уздыру турында Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән башлана һәм кимендә 21 көннән соң тәмамлана.»;

г) 4.4 пунктның 4.4.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.5. Конкурсның беренче этабының тәмамлану шарты билгеләнгән таләпләргә туры килүче ике һәм аннан да күбрәк кандидат булудан гыйбарәт, бу киләчәктә кандидатларны сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 көн кала, конкурс уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) хәбәр җибәрә.»;

д) 4.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңмәгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителсә, әлеге зат ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс игълан ителгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы керә торган төркемнең граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен

Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.»;

е) 4.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурста катнашучы кандидатларга кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә хәбәр ителә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шулай ук Министрлык үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасы сайтында урнаштыра.

Кандидат Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять бирергә хокуклы;»;

ж) Нигезләмәнең 4 нче кушымтасының «г» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе (хезмәт эшчәнлегенә беренче мәртәбә башкарыла торган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы бүтән документлар;

белеме һәм квалификациясе турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча – өстәмә һөнәри белеме нәтиҗәләре буенча квалификациясе артуны яисә бирелүне таныклый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документларның күчермәләре, алар нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган булырга тиеш;».

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Аверьянова Э.М.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы М.Х. Хәсәновка йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова